М Э Р
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**10.01.2017**

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№ 02-03-01**

«Зеленодольск» сәнәгать мәйданчыгын төзү. Автомобиль юлларын төзү. Инженерлык инфраструктурасы төзү» проектының линия объектлары буенча территорияне планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында..

Җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең уңай яшәү шартларына, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45, 46 маддәләре нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Минем инициатива буенча «Зеленодольск» сәнәгать мәйданчыгын төзү. Автомобиль юлларын төзү. Инженерлык инфраструктурасын төзү" проектының линия объектлары буенча территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне 14.02.2017 билгеләргә.
2. Зеленодольск шәһәренең гавами тыңлауларын үткәрү урынын һәм вакытын Ленин урамы, 41а йорты, 405 каб. 16.00 сәгатькә.билгеләргә.
3. 2017 елның 14 гыйнварына кадәр әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга һәм Зеленодольск муниципаль районының рәсми (pravo.tatarstan.ru) сайтында, Интернет челтәрендә урнаштырырга.
4. Җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт алу мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр, гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар МБУ «Зеленодольск муниципаль районының Архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» да чыгыш ясау хокукы белән мөрәҗәгать итү хокукы белән, түбәндәге адрес буенча: ТР, Зеленодольск ш., Ленин урамы, 41а йорты, каб. №211 (эш көннәрендә 9:00 дән 17:00 сәгатькә кадәр.) тел. /факс: (84371) 4-26-77. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга заявкалар бирү вакыты - 09.01.2017 кадәр.
5. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына:

5.1. «Зеленодольск» сәнәгать мәйданчыгын төзү. Автомобиль юлларын төзү, әлеге карар нигезендә инженерлык инфраструктурасы төзү.проектының линия объектлары буенча территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

5.2. 21.02.2017 елдан да соңга калмыйча гавами тыңлауларның нәтиҗәләрен бастырып чыгарырга;

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә.
7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Зеленодольск шәһәре мэры** **А.В. Тыгин**